**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары* 2021-2022 нче уку елы 7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

## I. Тестны эшләгез. (10 балл)

1. Сузыкларның калынлыкта яки нечкәлектә ярашуы нәрсә ул? (**1 балл**)

а) авазлар охшашлану

**ә) рәт гармониясе**

б) аваз кыскару

в) иренләшү гармониясе

2. Иренләшкән сузык авазны табыгыз. (**1 балл**)

**а) [о]**

ә) [ы]

б) [и]

в) [э]

3. *Көе* сүзендә е хәрефе ничек укыла? (**1 балл**)

а) [й ы]

ә) [й о]

б) **[й ө]**

в) [й е]

4. Позицион аваз үзгәрешләренә нәрсә керә? (**1 балл**)

а) ассимиляция

ә) аккомодация

**б) редукция күренеше**

в) дөрес язу кагыйдәләре

5. Алдан [й] яки [w] авазы, аннан соң сузык аваз килсә,  (**1 балл**)

**а) бу күтәрелмә дифтонг дип атала**

ә) төшерелмә дифтонг дип атала

б) трифтонглар дип атала

в) иренләшү гармониясе була

6. Ойконимия фәне нәрсәне өйрәнә? (**1 балл**)

а) географик атамаларны

ә) кеше исемнәрен

**б) авыл, шәһәр, торак пункт исемнәрен**

в) сулык атамаларын

7. *Кататься как сыр в масле* фразеологизмының татар телендәге тәрҗемәсен табыгыз. (**1 балл**)

а) баштан чыкмау

ә) иренендә сөт кипмәү

б) телне йоту

**в) авыз балда-майда**

8. Күчерелмә мәгънәдәге сүзләрне табыгыз. (**1 балл**)

а) алтын балдак

ә) җил исә

**б) җил елый**

в) авыр сумка

9. *Кайтаваз* сүзенең синонимын табыгыз. (**1 балл**)

а) кычкыру

**ә) яңгыравык**

б) үкерү

в) акыру

10. Антропонимика нәрсәне өйрәнә? (**1 балл**)

а) күк җисемнәре атамаларын

ә) хайван кушаматларын

**б) кеше исемнәрен, кушамат, фамилияләрне**

в) географик объект атамаларын

## II. Теоретик бирем (15 балл)

**Антонимнар һәм аларның төрләре турында языгыз һәм мисаллар китерегез.**

Капма-каршы мәгънәле сүзләр антонимнар дип атала: әйе — юк, көн — төн, язын — көзен, ата — ана, ак — кара, ача — яба.

Сөйләмдә кулланылышлары ягыннан антонимнарны тел антонимнарына һәм контекстуаль антонимнарга бүлеп йөртәләр.

**Тел антонимнары** сүзнең төп мәгънәләре буенча капма-каршы булалар: Ачның хәлен тук белмәс.

**Контекстуаль антонимнар** контекстта гына антоним булып киләләр. Аерым торганда, алар антоним булудан туктый: Башын югары күтәреп, Хәмис каршына торып басты. Болай басканда буй да бераз үскән, курку да кимегән.

Антонимнар ярдәмендә парлы сүзләр дә ясала: ут-су, яз-көз, дус-дошман, көн-төн, ата-ана, аклы-каралы.

## III. Гамәли-иҗади бирем (25 балл)

Айдар иң рәнҗетелгән, иң кыйналган малай булгандыр инде, аның белән дуслашырга теләүче юк. Дөресен генә әйткәндә, Хәмистән куркалар, качалар. Ләкин Айдарның бер иптәше бар. Ул — ятимнәр йортының мал абзарында яшәүче Кызылканат кушаматлы ат, аның якын дусты. Бу йорттагы бөтен хуҗалык эшләрен шул ат башкара, шул ат эшли. Ни өчен

Кызылканатмы? Кып-кызыл төстә ул. Чапканда озын яллары ике якка таралып, җилфердәп китә! Чын канатлар кебек, җилфер-җилфер килә.

Айдар бүген дә ат янына керәчәк, печән салачак, су китерәчәк, ялын тарап куячак. Аңа ятимнәр йортындагы яңалыкларны сөйләячәк. Әлбәттә, туган көне булмавы хакында да әйтәчәк ул Кызылканатка.

Г. Гыйльмановтан

1. ***Ятим*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(5 балл)**

**Ятим [й ә т и́ м]**

Я - тим

Х ә р е ф л ә р: я, т, и, м

А в а з л а р:

[й] — парсыз яңгырау тартык аваз, сонор, тел уртасы тартыгы;

[ә] — алгы рәт, озын, иренләшмәгән сузык аваз;

[т] — саңгырау тартык аваз, яңгырау пары — [д], тел алды тартыгы;

[и] — алгы рәт, озын, иренләшмәгән сузык аваз;

[м] — парсыз яңгырау тартык аваз, сонор, ирен-ирен тартыгы, борын авазы;

---

4 х., 5 ав.

2. *Кызылканат* сүзе ничек ясалган? Ясалышы ягыннан ул нинди сүз? **(2 балл)**

*Кызыл* һәм *канат* сүзләрен кушу юлы белән ясалган, кушма сүз.

3. *Җилфердәү* сүзенең синонимнарын языгыз. **(4 балл)**

**Җилфердәү -** чайкалу, тибрәнү, җилфер-филфер килү (итү), селкенү.

4. Җөмләне татар теленә хас булган тәртиптә үзгәртеп языгыз. (**2 балл**)

Әлбәттә, туган көне булмавы хакында да әйтәчәк ул Кызылканатка.

Әлбәттә, туган көне булмавы хакында да ул Кызылканатка әйтәчәк.

5. *“Яшьтәшләрең белән ничек дуслашасың?”* дигән сорауга җавап итеп, 11-12 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. **(12 балл)**